КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 4 март г.Казань № 149

2019 – 2022 елларга Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасын формалаштыру һәм үстерү концепциясен һәм Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасы субъектларының ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлеге регламентын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2019 – 2022 елларга Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасын формалаштыру һәм үстерү концепциясен;

Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасы субъектларының ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлеге регламентын.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 4 март, 149 нчы
карары белән расланды

# 2019 – 2022 елларга Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасын формалаштыру һәм үстерү концепциясе

## I. Гомуми нигезләмәләр

2019 – 2022 елларга Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасын формалаштыру һәм үстерү концепциясе (алга таба – Концепция) Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтүне үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыруның максатларын, бурычларын, принципларын һәм төп юнәлешләрен билгели.

Концепция Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасын үстерүгә юнәлдерелгән чараларны эшләгәндә дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеген интеграцияләү өчен нигез булып тора.

Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтү кеше хокукларын тәэмин итә торган һәм гражданнарга карата Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән күздә тотылган дәүләт гарантияләрен тормышка ашыра торган бердәм дәүләт сәясәте кысаларында гамәлгә ашырыла.

Россия җәмгыятенең хәзерге торышы, социаль-икътисадый трансформацияләр, яңа сәяси чынбарлыклар, массакүләм мәгълүмат чаралары экспансиясе халыкның рухи тормыш рәвешенә сизелерлек йогынты ясый, бик күп идея-әхлакый ориентирларны яңадан карап чыгу процессларын, яңа рухи кыйммәтләрне булдыруны һәм үзләштерүне стимуллаштыра. Хәзерге вакытта түбәндәге рисклар төрләре актуальләшә: уенга һәм интернетка бәйлелек арту; десоциализацияләү, виктимлык, көчләү, агрессия, яшьләрнең хокукка каршы гамәлләр кылу һәм антисоциаль тотышы күренешләре; экстремистлык һәм террорчылык юнәлешендәге тискәре субкультуралар үсү, психоактив матдәләрне куллanышка җәлеп итү; суицидаль тотыш; җенси тормышны иртә башлап җибәрү; этникара киеренкелек һәм милләтара низаглар; төрле мәдәниятләрдәге һәм төрле яшь төркемнәрендәге кешеләрнең аралашуында толерантлык кимү һәм башкалар.

Социаль-психологик киеренкелек дәрәҗәсен минимальләштерү һәм кешеләрнең психологик сәламәтлеген ныгыту максатларында, халыкка психологик ярдәм күрсәтүнең үсеш алган системасы кирәк.

## II. Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасының хәзерге торышы

Татарстан Республикасында соңгы елларда Татарстан Республикасындагы халыкка психологик хезмәт күрсәтүче төрле, шул исәптән дәүләткә карамаган

милек формаларындагы структуралар оештырылды. Әмма бу структураларның эш нәтиҗәлелеге ведомствоара таркаулык, халыкның начар мәгълүматлы булуы, норматив хокукый, оештыру-методик яктан һәм кадрлар белән тәэмин итү яраштырылмау, аның бердәм системасы булмау аркасында шактый түбән дәрәҗәдә тора.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында, тулаем Россиядәге кебек үк, халыкка психологик ярдәм күрсәтүнең гамәлдәге системасына хәл итүне таләп итә торган түбәндәге проблемаларның тулы бер комплексы хас:

психологик ярдәм күрсәтү фрагментар характерда булу, ул шәхси мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгән булу;

психологик ярдәм күрсәтүнең аерым юнәлешләре буенча технологик яктан тәэмин итү дисбалансы, бу аны системалы оештыруны авырлаштыра;

психологларның һөнәри позицияләренең килештерелмәгән булуы һәм аларның функциональ аерылган булуы;

халыкка психологик ярдәм күрсәтү өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы белгечләрнең шактый өлешенең һөнәри осталык дәрәҗәсе җитәрлек дәрәҗәдә булмау;

халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасы субъектлары хезмәттәшлегенең бердәм тәртибе булмау;

халыкка психологик ярдәм күрсәтү һәм аның психологик халәтен диагностикалау технологияләренең фәнни-методик яктан тәэмин итү системалы булмау;

җәмгыятьнең социаль-психологик киеренкелеген нәтиҗәле профилактикалауны гамәлгә ашырырга сәләте, психотерапия әзерлеге булган профессионаллар җитәрлек дәрәҗәдә булмау;

Татарстан Республикасында административ территорияләрдә психологик ярдәм күрсәтү дәрәҗәсе һәм сыйфаты тигез булмау;

халыкка психологик ярдәм күрсәтү өлкәсендә белгечләр эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләүнең төп күрсәткечләре системасы булмау.

Халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасы эшчәнлеге буенча норматив хокукый базаның тиешле дәрәҗәдә эшләнмәгән булуы билгеләп үтелә.

Шулай итеп, психологик ярдәмне нәтиҗәле һәм сыйфатлы итеп күрсәтү максатларында, эшчәнлеге Татарстан Республикасы халкының психологик таләпләре һәм ихтыяҗларының барлык спектрын канәгатьләндерүгә юнәлдерелгән максатчан система эшчәнлеген үстерү һәм алга таба камилләштерү кирәк.

## III. Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасы эшчәнлеген формалаштыру һәм үстерү максаты, бурычлары һәм принциплары

Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасы субъектлары (алга таба – Система субъектлары) булып түбәндәгеләр тора:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары (Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы; Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт

министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы);

Татарстан Республикасындагы террорчылыкка каршы комиссия һәм муниципаль берәмлекләрдәге террорчылыкка каршы комиссияләр (килешү буенча);

Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе, муниципаль берәмлекләрдәге балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре (килешү буенча);

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (килешү буенча);

төп һәм өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыручы белем бирү оешмалары, медицина оешмалары, гадәттән тыш хәлләр, яшьләр сәясәте һәм спорт, мәдәният, социаль яклау һәм халыкны эш белән тәэмин итү оешмалары (килешү буенча);

эшчәнлеге халыкның психологик проблемаларын хәл итүгә юнәлдерелгән теләсә кайсы ведомство буйсынуындагы учреждениеләр, җәмгыятьләр, иҗтимагый оешмалар һәм хәрәкәтләр, фондлар (килешү буенча).

Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасын формалаштыру һәм үстерү максаты – халыкның социаль яклануын һәм психологик иминлеген тәэмин итү, гражданнарның квалификацияле психологик ярдәм алуга хокукларын тормышка ашыру гарантияләрен булдыру.

Куелган максатны тормышка ашыру өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:

халыкның психологик сәламәтлеген саклау һәм ныгыту өчен шартлар тудыру;

Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтү өлкәсендә норматив хокукый базаны формалаштыру һәм үстерү;

Татарстан Республикасында халыкның психологик проблемаларын хәл итүдә башкарма хакимият органнарының, җирле үзидарә органнарының, гамәли, фәнни, белем бирү, эксперт оешмаларының, иҗтимагый берләшмәләрнең ведомствоара хезмәттәшлеген һәм хезмәттәшлек итүен тәэмин итү;

җәмгыятьтәге психологик киеренкелекне индикатив күзәтүне оештыру һәм системалы тәэмин итү;

халыкка психологик аң-белем бирүне оештыру, халыкның база психологик белемнәре дәрәҗәсен күтәрү;

халыкка үз вакытында һәм бөтен җирдә һөнәри психологик ярдәм күрсәтүне оештыру һәм гамәлгә ашыру;

мәдәниятара компетентлыкны һәм толерантлыкны формалаштыруда, ксенофобияне, экстремизмны, этникара низагларны профилактикалауда катнашу;

халыкка психологик ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт тикшерүен оештыру һәм тормышка ашыру;

халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасы субъектлары эшчәнлеген мәгълүмати-методик, фәнни һәм кадрлар белән тәэмин итүне оештыру;

халыкка психологик ярдәм күрсәтү өлкәсендә эшчәнлекнең бюджеттан тыш юнәлешләрен үстерү һәм аларга булышлык күрсәтү.

Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасын үстерүнең төп принциплары булып түбәндәгеләр тора:

психологик ярдәм күрсәтүне оештыруда һәм гражданнарга катлаулы тормыш шартларында аннан файдалану хокукын гарантияләүдә дәүләт башлангычларының өстенлеге;

психологик юнәшлештәге хезмәтләр, учреждениеләр һәм оешмалар эшчәнлеге белән дәүләт тарафыннан идарә итү һәм аны яраштыру механизмы бердәмлеге;

җәмгыятьнең психологик проблемаларын комплекслы чишү өчен ведомство мәнфәгатьләрен һәм мөмкинлекләрен интеграцияләү;

система субъектлары эшчәнлеген дифференциацияләү, аларның компетентлыгын һәм җаваплылыгын арттыру;

халыкка күрсәтелә торган психологик хезмәтләрнең системалы, күчүчән һәм югары сыйфатлы булуы;

халыкның психологик ярдәмнән файдалануы ирекле һәм һәркем өчен файдалана алу мөмкинлеге булу;

халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасы субъектлары эшчәнлегенең социаль һәм икътисадый максатчанлыгы.

## IV. Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасын формалаштыруның һәм үстерүнең өстенлекле юнәлешләре

Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасы алдында торган бурычларны хәл итү өчен аны үстерү буенча түбәндәге өстенлекле юнәлешләр билгеләнде: норматив хокукый җайга салу, оештыру-идарә итү ягыннан тәэмин итү, финанслар белән тәэмин итү, кадрлар белән тәэмин итү, фәнни-методик һәм мәгълүмати яктан тәэмин итү, ведомстволар арасында һәм ведомстволар эчендә хезмәттәшлек итү өчен шартлар тудыру.

Норматив хокукый җайга салу үз эченә психологик ярдәм күрсәтү системасы эшчәнлеген җайга салучы норматив хокукый базаны камилләштерүне ала.

Психологик ярдәм күрсәтү системасы эшчәнлеген норматив хокукый җайга салуның төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

халыкка психологик ярдәм күрсәтү өлкәсендә хокукый гарантияләр билгеләү;

система эшчәнлеген тәэмин итә торган, аның субъектларын яраштыруны һәм аларның үзара хезмәттәшлеген гамәлгә ашыра торган хокукый нормаларны формалаштыру;

халыкка күрсәтелә торган психологик хезмәтләрнең сыйфатын дәүләт һәм җәмәгать тикшерүендә тотуның хокукый нормаларын билгеләү.

Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасы эшчәнлеген норматив хокукый җайга салуны камилләштерү өчен түбәндәгеләр кирәк:

халыкка психологик ярдәм күрсәтү, хокук куллану тәҗрибәсе өлкәсендә норматив хокукый тәэмин итүнең хәзерге торышына анализ үткәрү;

психологик ярдәм күрсәтү системасын формалаштыру, эшләтү һәм үстерү процессларын җайга салучы норматив хокукый актларның мәгълүмати-белешмә характерындагы мәгълүматлар базасын булдыру һәм актуаль хәлдә тоту;

халыкка психологик ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча норматив хокукый актлар эшләү;

халыкка психологик ярдәм күрсәтү буенча гамәлдәге субъектларны инвентаризацияләү, аларның функционалын, структурасын һәм составын оптимальләштерү буенча тәкъдимнәр кертү;

Татарстан Республикасында халыкның психологик киеренкелеге дәрәҗәсен билгеләү индикаторларын эшләү.

Оештыру-идарә итү ягыннан тәэмин итү Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасын эшләтү максатларында бердәм һөнәри киңлек булдыру эшчәнлеген күздә тота.

Система субъектлары эшчәнлеген оештыру куелган максатларны өзлексез үтәүне, төрле юнәлешләр буенча психологик эшчәнлек шартларына һәм нәтиҗәләренә үзгәрешләр кертүне исәпкә алып, үз вакытында төзәтмәләр һәм төзәтүләр кертүне күздә тота.

Система субъектларының килештерелгән гамәлләр кылуын һәм аларны яраштыруны тәэмин итү максаты белән Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына халыкка социаль-психологик ярдәм күрсәтүнең дәүләт системасын формалаштыру һәм үстерү функциясе беркетелгән.

Системаның һәр төп юнәлешләре буенча эшчәнлеген оештыру Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан аларга йөкләнгән идарә функцияләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

Система субъектлары эшчәнлеген финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле бюджетлар акчасы, дәүләт программаларын тормышка ашыруга каралган акча, предприятиеләр һәм оешмалардан, фондлардан, иҗтимагый берләшмәләрдән, иганә ярдәменнән кергән акча, эшләр башкару һәм хезмәт күрсәтүләр нәтиҗәсендә алынган акча, бюджеттан тыш социаль проектларны тормышка ашыру һәм законнар белән тыелмаган башка чыганаклар исәбеннән гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Система субъектлары эшчәнлеген кадрлар белән тәэмин итү белгечләргә һөнәри белем бирүне һәм өстәмә һөнәри белем бирүне күздә тота һәм түбәндәге төп юнәлешләр буенча гамәлгә ашырыла:

белгечләргә һөнәри юнәлеш бирү һәм аларны психологик хезмәтләргә сайлап алу;

төп һәм өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыручы белем бирү оешмалары белән берлектә, төрле укыту формасындагы һөнәри югары белем бирүче мәгариф оешмаларында психологик белгечлекләр буенча белем бирү программаларын, технологияләрне, компетенцияләр паспортларын эшләү;

белгечләрне (психологларны, педагог-психологларны) өзлексез тәҗрибәи-юнәлешле әзерләү системасын камилләштерү һәм үстерү;

эшләүче белгечләрне (психологларны, педагог-психологларны) яңадан әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү;

төрле ведомство буйсынуындагы белгечләрне (психологларны, педагог-психологларны) аттестацияләү системасын булдыру;

остазлык институтын гамәлгә кертү һәм үстерү;

стажировка мәйданчыкларын формалаштыру;

белгечләрнең эмоциональ януын, шәхси һәм һөнәри деформацияләнүен профилактикалау;

төбәкара һәм халыкара хезмәттәшлек кысаларында белгечләр (психологлар, педагог-психологлар) фәнни һәм җитештерү стажировкаларын үтү, тәҗрибә белән алмашу.

Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасын фәнни-методик һәм мәгълүмати яктан тәэмин итү халыкка психологик ярдәм күрсәтү өлкәсендә гамәли эшчәнлекне оештыруга карата фәнни якын килүне формалаштыруга, психологик хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә һөнәри эшчәнлек өчен методологик, методик, мәгълүмати нигезләр әзерләүгә, халыкның психологик культурасын үстерүгә юнәлдерелгән.

Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасын фәнни-методик һәм мәгълүмати яктан тәэмин итү түбәндәге төп юнәлешләр буенча гамәлгә ашырыла:

җәмгыятьтә психологик киеренкелек мониторингын үткәрү;

халыкка психологик ярдәм күрсәтүче учреждениеләр һәм белгечләр эшчәнлеген исәпкә алу һәм аларның статистика хисаплылыгы системасын камилләштерү һәм үстерү;

эшнең нәтиҗәле формаларын һәм ысулларын эшләү, апробацияләү һәм гамәлгә кертү;

инновацион тәҗрибәләрне, эксперименталь модельләрне формалаштыру, халыкка психологик ярдәм күрсәтү өлкәсендә иң яхшы тәҗрибәләрне гомумиләштерү һәм тарату;

Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтүче белгечләр, учреждениеләр һәм оешмалар эшчәнлеген бәяләү буенча эксперт эшен оештыру һәм үткәрү;

конференцияләр, семинарлар, «түгәрәк өстәлләр» һәм фәнни-гамәли, методик, оештыру һәм уку-укыту характерындагы башка чаралар оештыру һәм үткәрү;

система эшчәнлегенең төрле юнәлешләре буенча халыкка психологик ярдәм күрсәтү өлкәсендә үз илебез һәм чит ил тәҗрибәсен фәнни-методик яктан гомумиләштерү һәм бу нигездә иң яхшы тәҗрибәләрне гамәлгә кертүне оештыру;

Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтү һәм халыкның психологик культурасын үстерү буенча уңай тәҗрибәне пропагандалау өчен массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлекне оештыру.

Белгечләрнең ведомствоара һәм дәрәҗәара хезмәттәшлеге өчен шартлар тудыру халыкка психологик ярдәм күрсәтүнең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән, бу түбәндәгеләрне күз алдында тота:

төрле ведомстволардагы психологик хезмәтләрнең ведомствоара хезмәттәшлеге механизмын булдыруны;

төрле ведомстволардагы психологик хезмәтләрнең уртак эшчәнлеге өчен норматив-хокукый һәм ресурс базасын эшләүдә һәм камилләштерүдә ведомстволар көчләрен яраштыруны.

## V. Концепцияне тормышка ашыру механизмы һәм ресурслары

Концепцияне тормышка ашыру Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтүнең бердәм стандартларыннан, күрсәтелә торган

психологик хезмәтләрнең сыйфатын тикшереп торуның һәм психологларны аттестацияләүнең бердәм системасыннан файдалануга нигезләнгән. Бу шушы Концепциядә куелган бурычларны хәл итү өчен Татарстан Республикасының бөтен территориясендә халык өчен һәр урында файдалана алырлык психологик хезмәтләр оештыруны һәм аларның эшкә сәләтле хәлдә эшләвен тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Концепция аны аерым дәүләт, муниципаль һәм ведомство программаларын һәм проектларын эшләү рәвешендә детальләштерүне күздә тота.

Система субъектлары эшчәнлеген үстерү Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасы субъектларының ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлеге регламенты белән тәэмин ителә.

Халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасын формалаштыру һәм үстерү, түбәндәге функцияләрне тормышка ашырып, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы тарафыннан тәэмин ителә:

халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасын үстерү;

төрле ведомство буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлеген мониторинглау (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы);

норматив хокукый актларның мәгълүмати-белешмә характерындагы мәгълүматлар базасын формалаштыруда һәм актуаль хәлдә булуны тәэмин итүдә катнашу;

психологик хезмәтләр күрсәтүче учреждениеләр һәм белгечләр эшчәнлеген исәпкә алу һәм аларның статистика хисаплылыгы системасын камилләштерү һәм үстерү;

психологлар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген цифрлы бәяләү;

психологик хезмәтләр күрсәтүне исәпкә алуның бердәм автоматлаштырылган системасын алып бару (гражданнарның һәм аларга күрсәтелә торган психологик хезмәтләр күләменең шәхсиләштерелгән исәбен алу);

психологик хезмәтләр күрсәтүче оешмалар реестрын алып бару.

## VI. Халыкка психологик ярдәм күрсәтү юнәлешләре һәм формалары

Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасы субъектлары эшчәнлеге берничә төп юнәлешләргә бүленә, шул исәптән:

1. Кешенең үз-үзен тотышын һәм эмоциональ халәтен коррекцияләүдән, үзгәрүчән социаль шартларга адаптацияләүдән, стресс халәтләрен, шәхес арасындагы низагларны һәм психик дискомфортның башка хәлләрен җиңеп чыгу күнекмәләрен өйрәнүдән, шәхси ресурсларны эзләүдән гыйбарәт психологик ярдәм күрсәтү.

2. Үсеп килүче буынны һәм яшьләрне тәрбияләү, аларны социальләштерү һәм аларга һөнәри юнәлеш бирү өчен уңай шартлар тудыруга юнәлдерелгән халыкка психологик-педагогик ярдәм күрсәтү. Ул балаларны тәрбияләүдә төрле кыенлыклар кичерүче гаиләләргә, белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучыларның (балалар, ата-аналар (законлы вәкилләр) педагогик хезмәткәрләр) психологик кризисы мөмкин

булуын булдырмауга юнәлдерелгән. Психологик-педагогик ярдәм күрсәтү үсеп килүче буынның психик үсешендәге проблемаларын, шәхеснең, яшьтәшләр, өлкәннәр, әйләнә-тирә дөнья белән үзара мөнәсәбәтләрнең формалашу процессын үз эченә ала. Бу ярдәм күрсәтү төре шулай ук гаиләдә шәхес үсешенең уңай шартларыннан читләштерелгән балаларның психик үсешенә ярдәм күрсәтә.

3. Психологик дискомфорт һәм эмоциональ тотрыксызлык тудыра торган авыр тормыш хәлендә калган гражданнарга психологик булышлык күрсәтүне тәэмин итә торган халыкка психосоциаль ярдәм күрсәтү. Бу ярдәм күрсәтү төре үз-үзенә, әйләнә-тирәгә һәм җәмгыятькә карата адекват мөнәсәбәт формалаштыру (шул исәптән гаиләдә, хезмәт коллективында мөнәсәбәтләрне психологик яктан төзәтүне, шулай ук шәхеснең күзаллауларын төзәтүне кертеп) максаты белән кешенең социаль-психологик һәм шәхси сыйфатларын диагностиклауны, тернәкләндерүне һәм үстерүне күздә тота.

Бу ярдәм күрсәтү төре шулай ук социаль, мораль-әхлакый, хокукый характердагы тайпылышлары булган, хокукка каршы гамәлләр кылуга, башка асоциаль һәм антисоциаль тәртипкә һәвәс булган асоциаль тотышлы затларны социаль-психологик тернәкләндерүгә, irектән мәхрүм итү урыннарында булуның психологик нәтиҗәләрен тернәкләндерүгә юнәлдерелгән.

4. Социаль статусына, яшәү урынына карамастан гражданнарга ашыгыч һәм аноним психологик ярдәм күрсәтүне тәэмин итә торган халыкка кичектергесез психологик ярдәм күрсәтү. Түбәндәге психологик проблемаларны үз вакытында хәл итүгә юнәлдерелгән: психологик дискомфортны, кешеләрдә агрессия (аутоагрессия һәм суицидаль тәртипне кертеп) дәрәҗәсен киметү, халыкның психологик сәламәтлеген һәм психологик якланганлыгы атмосферасын ныгыту, җәмгыятьтә психологик культура формалаштыру. Кичектергесез психологик ярдәм күрсәтүнең төп бурычы – ул шәхес һәм җәмгыять өчен куркыныч тудыра торган кискен эмоциональ хәлне булдырмау. Бу ярдәм күрсәтү төре күндезге формада да, читтән торып да («ышаныч телефоны» буенча) күрсәтелә ала.

5. Гадәттән тыш хәлләрдә зыян күргән затларга һәм аларның гаилә әгъзаларына кичектергесез һәм озак вакытлы психологик ярдәм күрсәтү.

6. Террорчылык һәм экстремистлык идеологиясе йогынтысына эләккән затларны социаль-психологик реадаптацияләү һәм ресоциализацияләү, террорчылык характерындагы һәм экстремистлык юнәлешендәге җинаятьләр өчен хөкем ителгәннәрнең балаларына һәм якыннарына тернәкләндерә торган ярдәм күрсәтү.

7. Белем бирү мохитенең психологик иминлеген мониторинглау.

---

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 4 март, 149 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасы субъектларының ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлеге регламенты

1. Бу Регламент Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлеген оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата, социаль хезмәт күрсәтүләргә карамый торган психологик ярдәм күрсәтү буенча үткәрелгән чаралар турында мәгълүмат бирүнең (шул исәптән электрон рәвештә) эчтәлегенә, формаларына һәм шартларына карата таләпләр билгели.

Бу Регламент «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 ел, 28 декабрь, ФЗ-442 нче, «Дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) һәм муниципаль тикшерүне гамәлгә ашырганда юридик затларны һәм индивидуаль эшмәкәрләрне яклау турында» 2008 ел, 26 декабрь, ФЗ-294 нче, «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 ел, 27 июль, ФЗ-210 нчы (алга таба – ФЗ-210 нчы Федераль закон) федераль законнар нигезендә, шулай ук 2019 – 2022 елларга Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасын формалаштыру һәм үстерү концепциясе нигезендә эшләнде.

2. Бу Регламентта кулланыла торган төп төшенчәләр:

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек – ведомствоара хезмәттәшлектә катнашучыларга халыкка психологик ярдәм күрсәтү турындагы мәгълүматны (күрсәтелгән хезмәтләр исемен, аларны күрсәтү вакытын, күләмен һәм даимилеген кертеп) оператив рәвештә бирү;

Үз штатында психологлары булган Система субъектлары психологик ярдәм күрсәтүче система субъектлары булып тора;

Психологик адаптацияләүнең индивидуаль картасы (алга таба – индивидуаль карта) – бу гражданның хәленә, аның психологик проблемасы үзенчәлегенә анализ ясаганда психолог тарафыннан эшләнә торган һәм, граждан белән бергәләп, формасы, төре һәм күләме өлешендә күрсәтелә торган психологик ярдәм билгеләнгән документ;

«Психологик ярдәм күрсәтү системасы» мәгълүмат системасы (алга таба – мәгълүмат системасы) – бу психологик ярдәм күрсәтү буенча күрсәтелгән хезмәтләрне исәпкә алу өчен бердәм мәгълүмат кыры сыйфатында оештырылган мәгълүмат системасы;

Татарстан Республикасы психологлары реестры – психологик ярдәм күрсәтүче белгечләрнең фамилияләре күрсәтелгән реестры.

3. Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасының яраштыручысы булып Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы тора.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучылар – Системаның барлык субъектлары.

4. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек Татарстан Республикасында психологик ярдәм күрсәтү системасын яраштыру максатларында гамәлгә ашырыла һәм түбәндәге бурычларны хәл итүне күздә тота:

бердәм мәгълүмат кырын булдыру;

психологик ярдәм күрсәтелгән гражданнарны исәпкә алу;

психологик ярдәм күрсәтү өлкәсендә күрсәтелгән хезмәтләрне исәпкә алу;

Татарстан Республикасы психологлары реестрын формалаштыру һәм алып бару;

халыкка психологик ярдәм күрсәтүче ведомствоара хезмәттәшлектә катнашучылар тарафыннан алга таба яраштыруны оештыру өчен халыкка психологик ярдәм күрсәтү буенча күрсәтелгән хезмәтләр турындагы мәгълүматны оператив бирүне оештыру;

мәгълүматлар җыю һәм эшкәртү өчен кирәкле хисаплылык системасын һәм формаларын эшләү;

мәгълүмат агымнары һәм алынган мәгълүматны эшкәртү системасын оештыру;

максатчан күрсәткечләр белән фактта ирешелгән нәтиҗәләргә анализ үткәрү;

ресурслардан файдалануның нәтиҗәлелегенә анализ үткәрү;

Татарстан Республикасында психологик вәзгыятьне мониторинглауны оештыру.

5. Система субъектлары (шул исәптән психологик ярдәм күрсәтүче субъектлар) түбәндәге функцияләрне башкара:

гражданнарның яки аларның законлы вәкилләренең психологик ярдәм күрсәтү турындагы мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү;

мәгълүмат системасы ярдәмендә психологик ярдәм күрсәтүгә мохтаҗ булган граждан турында мәгълүмат җибәрү.

Халыкка психологик ярдәм күрсәтүче система субъектлары түбәндәге функцияләрне башкара:

профессиональ психологик ярдәм күрсәтү;

мәгълүмат системасында күрсәтелгән психологик хезмәтләрне исәпкә алуны алып баруны тәэмин итү.

6. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы мәгълүмат системасындагы мәгълүматлар нигезендә Татарстан Республикасында психологик ярдәм күрсәтү системасын яраштыруны, шул исәптән мәгълүматларны җыю һәм эшкәртү өчен кирәкле хисаплылык системасын һәм формаларын эшләүне; мәгълүмат агымнары һәм алынган мәгълүматны эшкәртү системасын оештыруны; психологик ярдәм күрсәтүнең санлы һәм сыйфатлы күрсәткечләрен исәпкә алуны, максатчан күрсәткечләр белән фактта ирешелгән нәтиҗәләргә анализ үткәрүне; ресурслардан файдалану нәтиҗәлелегенә анализ үткәрүне; Татарстан Республикасында психологик вәзгыятьне мониторинглауны оештыруны; психологик хезмәтләр күрсәтүче оешмалар реестрын алып баруны гамәлгә ашыра.

7. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибе психологик ярдәм күрсәткәндә ведомствоара хезмәттәшлек итүдә катнашучыларның үзара килешенгән гамәлләрен гамәлгә ашыруны күздә тота.

Психологик ярдәм күрсәтү кысаларында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучылар тарафыннан эшчәнлекнең түбәндәге төрләре гамәлгә ашырыла:

гражданнарның яки аларның законлы вәкилләренең психологик ярдәм күрсәтү турындагы мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү;

индивидуаль карта эшләү һәм аны тормышка ашыру;

психологик хезмәтләр күрсәтү;

психологик ярдәм күрсәтү буенча күрсәтелгән хезмәтләрне исәпкә алуны алып бару;

ведомствоара хезмәттәшлектә катнашучылар үзара хезмәттәшлек иткәндә техник шартларны тәэмин итү;

мәгълүмат системасында күрсәтелгән хезмәтләр исәпкә алуны алып баруны тәэмин итү;

Татарстан Республикасы психологлары реестрын формалаштыру һәм алып бару.

8. Катнашучыларның ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлеге түбәндәге формаларда гамәлгә ашырыла:

мәгълүмат алмашу, сораулар буенча мәгълүмат бирү, шул исәптән электрон рәвештә;

мәгълүмати хезмәттәшлек турында килешүләр төзү;

хисап һәм аналитик формаларын бергәләп эшләү;

психологик ярдәм күрсәтү һәм психологик ярдәм күрсәтү системасын яраштыру мәсьәләләре буенча семинарлар, киңәшмәләр, эшче төркемнәр, уртак чаралар үткәрү һәм катнашу;

уртак эшчәнлекне планлаштыру;

башка формалар.

9. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучыларның үзара хезмәттәшлеге Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы белән төзелгән килешүләр нигезендә гамәлгә ашырыла. Килешүдә түбәндәгеләр билгеләнергә тиеш:

ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлектә турыдан-туры катнашучылар;

тапшырыла торган мәгълүмат исемлеге һәм төре;

мәгълүматлар тапшыру вакытлары;

килешүдә катнашучыларның килешү белән күздә тотылган чараларны үткәрү барышында шәхси мәгълүматлар куркынычсызлыгын сакламаган, мәгълүматны үз вакытында (дөрес итеп) бирмәгән өчен җаваплылыгы;

психологик хезмәтләр күрсәтү исемлеге һәм шартлары.

10. Үзара хезмәттәшлек түбәндәге эзлеклелектә гамәлгә ашырыла:

| Т/с | Мәгълүмат чыганагы | Башкарыла торган операциянең һәм тапшырыла торган мәгълүматның кыскача тасвирламасы | Тапшыру формасы | Тапшыру вакыты | Мәгълүмат саклау урыны |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1. | Система | гражданнарның яки | электрон, | граждан | мәгълүмат |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | субъектлары (шул исәптән психологик ярдәм күрсәтүче субъектлар) | аларның законлы вәкилләренең психологик ярдәм күрсәтү турындагы мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү; мәгълүмат системасы ярдәмендә психологик ярдәм күрсәтүгә мохтаҗ булган граждан турында мәгълүмат җибәрү | кәгазь | мөрәҗәгать итүгә карап | системасы |
| 2. | Психологик ярдәм күрсәтүче система субъектлары | психологик ярдәм күрсәтү өчен исәпкә кую | электрон | граждан мөрәҗәгать иткән көндә бер эш көне эчендә | мәгълүмат системасы |
| | | индивидуаль картаның формасын, психологик хезмәт күрсәтүләрнең төрен, күләмен һәм даимилеген, күрсәтү графигын күрсәтеп, әлеге картаны эшләү | | гражданны исәпкә алу көненнән соң килүче бер эш көне эчендә | |
| | | эшләнгән индивидуаль карта нигезендә күрсәтелгән психологик хезмәт турында хисап | | психологик хезмәт күрсәткән көндә | |
| | | гражданга психологик ярдәм күрсәтү нәтиҗәләре турында бәяләмә формалаштыру | | индивидуаль картаның барлык пунктларын үтәгән көндә | |
| | | белемен, өстәмә белемен, квалификациясен, практик эш тәҗрибәсен, эш урынын, эш урыны адресын, эшчәнлек чорын күрсәтеп, халыкка психологик хезмәт күрсәтүче белгечләр турында мәгълүмат | | эшкә кабул иткән көндә | |
| 3. | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы | психологик ярдәм күрсәтү системасын яраштыру, шул исәптән мәгълүмат агымнары һәм алынган мәгълүматны эшкәртү системасын оештыру;<br>психологик ярдәм күрсәтүнең санлы һәм сыйфатлы күрсәткечләрен исәпкә алу;<br>максатчан күрсәткечләр белән фактта ирешелгән | электрон, кәгазь | даими | Психологик ярдәм күрсәтүче система субъектларына мәгълүмат системасы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | | нәтиҗәләргә анализ үткәрү;<br>ресурслардан файдалану нәтиҗәлелегенә анализ үткәрү;<br>Татарстан Республика-сында психологик вәз-гыятьне мониторинг-лауны оештыру | | | |

11. Ведомствоара хезмәттәшлектә катнашучылар арасында бу Регламентның 10 пунктындагы таблицаның 1 пунктчасында күрсәтелгән мәгълүмат алмашу Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибе турында» 2012 ел, 7 август, 674 нче карары нигезендә электрон документ рәвешендә йә кәгазь чыганакта гамәлгә ашырыла.

Әгәр дә оешмага йә учреждениегә психологик ярдәм күрсәтү буенча хезмәтләр күрсәтү өчен ведомствоара хезмәттәшлектә катнашучыларның башкаларыннан документлар (мәгълүматлар) алырга кирәк булса, оешма йә учреждение тиешле хезмәттәшлектә катнашучыга документ рәвешендәге сорауны кәгазь чыганакта яки электрон рәвештә ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы ярдәмендә җибәрә (сорауда «Дәүләт сере турында» 1993 ел, 21 июль, 5485-1 нче Россия Федерациясе Законы нигезендә дәүләт серен тәшкил итә торган мәгълүмат булган очраклардан тыш).

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлектән файдаланып, психологик ярдәм күрсәтү өчен документлар (мәгълүматлар) бирү турындагы ведомствоара сорауның эчтәлеге ФЗ-210 нчы Федераль закон белән билгеләнгән таләпләргә туры килергә тиеш.

Социаль хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) социаль булышлык итүдә ярдәм күрсәтү өчен мөрәҗәгать иткән гражданнарның шәхси мәгълүматларын эшкәрткәндә ФЗ-210 нчы Федераль закон нигезендә конфиденциальлекне саклау ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында мәгълүмат биргәндә мәгълүмат алмашуның шарты булып тора.

---